КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 3 октябрь г.Казань № 1061

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 439 нчы карары белән расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 8 июнь, 439 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 11 август, 704 нче; 2021 ел, 15 ноябрь, 1077 нче; 2021 ел, 29 декабрь, 1312 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «2014 – 2024» саннарын «2014 – 2025» саннарына алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Вәкаләтле зат, заявкалар кабул ителә башлаган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

вәкаләтле органның исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

бу Тәртипнең 31 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган сайтның домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) битләр күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 10 пункты нигезендә авиаташучыларга карата таләпләр һәм авиаташучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 14 пункты нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләре;

авиаташучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибе, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасы;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогы;

сайлап алуда җиңүчене шартнамә төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчесен (җиңүчеләрен) билгеләү көненнән соң килүче 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авиаташучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Авиаташучы сайлап алуда катнашу өчен әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган сайлап алуны уздыру турында игълан итүдә күрсәтелгән срокта вәкаләтле органга вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча заявка бирә, ул шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә авиаташучы турында, авиаташучы биргән заявка турында мәгълүматны, авиаташучы турында сайлап алуга бәйле башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) рөхсәтне һәм түбәндәге документларны үз эченә ала:

эксплуатант сертификаты күчермәсен (күрсәтелгән документ авиаташучы тарафыннан күрсәтелмәгән очракта, вәкаләтле орган аны Федераль һава транспорты агентлыгында яисә аның территориаль органнарында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала);

Федераль һава транспорты агентлыгы белән әлеге Тәртипкә беркетелгән исемлектә күрсәтелгән субсидияләнүче маршрутларга карата федераль бюджеттан субсидияләр бирү турында төзелгән килешү күчермәсен;

авиаташучының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмавын раслый торган салым органы биргән белешмәне (күрсәтелгән документ авиаташучы тарафыннан күрсәтелмәгән очракта, вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә салым органында соратып ала);

авиаташучы җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм авиаташучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычының һәм Татарстан Республикасы алдындагы акча йөкләмәләре буенча кичектергесез (җайга салынмаган) башка бурычларының булмавын раслый торган авиаташучының мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмәсен;

авиаташучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм авиаташучының мөһере (булган очракта) белән теркәлгән авиаташучының үзгәртеп кору процессында булмавын (башка юридик затны авиаташучыга тоташтыру формасында үзгәртеп корудан тыш), ликвидацияләнүен, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәвен, авиаташучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын раслаган белешмә;

авиаташучы чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булып тормауны раслый торган, авиаташучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм авиаташучының мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә;

авиаташучының Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алмавын раслый торган, авиаташучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы кул куйган һәм авиаташучының мөһере (булган очракта) белән беркетелгән белешмә;

авиаташучының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, авиаташучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе.

Тапшырылган документларның күчермәләре авиаташучы тарафыннан таныкланырга тиеш.

Авиаташучы тәкъдим ителгән заявкаларда һәм документларда булган мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.»;

16 пунктының беренче абзацында «заявкаларны карау» сүзләрен «сайлап алу» сүзләренә алмаштырырга;

17 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының вәкаләтле орган тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^{1}$ һәм $269^{2}$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $28^{1}$ пункт өстәргә:

«$28^{1}$. Субсидия бирүнең нәтиҗәсенә ирешү мониторингын үткәрү, килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә һәм субсидия (контроль нокта) бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле проектны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларга ирешүдән чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрелә.»;

29 пунктта:

өченче абзацта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

32 пунктта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Тәртипнең 10 пунктындагы өченче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме бишенче һәм утыз тугызынчы абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе территориясендә һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һава транспорты оешмаларына субсидияләр бирү тәртибенә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 3 октябрь, 1061 нче карары редакциясендә)

2022 елга Татарстан Республикасы территориясеннән һәм (яки) территориясенә гамәлгә ашырыла торган һава транспорты белән төбәк эчендә пассажирлар йөртүнең субсидия бирелә торган маршрутлары исемлеге

| Т/с | Һава транспорты белән пассажирлар йөртү маршрутлары | | Атнага рейс-лар ешлы-гы | Елга рейс-лар ешлы-гы | Махсус тариф-ның чик зурлыгы, сум | Бер парлы рейска Татарстан Республикасы бюджетыннан авиапассажирлар йөртүчеләргә бирелә торган субсидия күләме, сум | Һавада йөртүләрне башкару чоры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | аэропорт җибәрүләр | аэропорт билгеләнеше | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Казан | Әстерхан | 2 | 55 | 6 123,0 | 139 726,6 | 02.01.2022 – 31.05.2022<br>01.10.2022 – 31.12.2022 |
| 2. | Казан | Барнаул | 2 | 72 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2022 – 30.06.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 3. | Казан | Волгоград | 2 | 36 | 5 157,0 | 117 431,1 | 02.01.2022 – 31.03.2022<br>01.11.2022 – 31.12.2022 |
| 4. | Казан | Махачкала | 2 | 55 | 8 055,0 | 223 336,25 | 02.01.2022 – 30.04.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5. | Казан | Кемерово | 2 | 60 | 10 953,0 | 223 336,25 | 02.01.2022 – 30.06.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 6. | Казан | Түбән Новгород | 4 | 147 | 2 741,0 | 61 691,13 | 02.01.2022 – 31.12.2022 |
| 7. | Казан | Самара | 2 | 90 | 2 258,0 | 50 543,38 | 02.01.2022 – 31.12.2022 |
| 8. | Казан | Пермь | 2 | 63 | 3 225,0 | 72 839,49 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 9. | Казан | Ярославль | 2 | 55 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.10.2022 – 31.12.2022 |
| 10. | Казан | Воронеж | 2 | 15 | 4 764,0 | 106 282,74 | 02.01.2021 – 30.04.2021 01.11.2021 – 31.12.2021 |
| 11. | Казан | Петрозаводск | 2 | 69 | 6 606,0 | 150 874,35 | 01.05.2022 – 30.09.2022 |
| 12. | Казан | Оренбург | 3 | 104 | 3 708,0 | 83 987,24 | 02.01.2022 – 20.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 13. | Казан | Орск | 3 | 30 | 4 674,0 | 106 282,74 | 21.05.2022 – 31.08.2022 |
| 14. | Казан | Яңа Уренгой | 2 | 63 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 15. | Казан | Сургут | 2 | 63 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 16. | Казан | Нижневартовск | 2 | 63 | 9 021,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 17. | Бөгелмә | Сургут | 2 | 63 | 8 055,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 18. | Бөгелмә | Яңа Уренгой | 2 | 63 | 9 987,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 19. | Бөгелмә | Ноябрьск | 2 | 63 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 20. | Бөгелмә | Нижневартовск | 2 | 63 | 8 538,0 | 366 125,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 21. | Бөгелмә | Усинск | 2 | 63 | 7 089,0 | 274 748,0 | 02.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 22. | Казан | Магнитогорск | 2 | 90 | 7 191,0 | 95 134,99 | 02.01.2022 – 31.12.2022 |
| 23. | Казан | Белгород | 2 | 51 | 6 123,0 | 139 726,6 | 02.01.2022 – 31.12.2022 |
| 24. | Казан | Элиста | 2 | 50 | 6 123,0 | 137 436,0 | 02.01.2022 – 31.12.2022 |
| 25. | Казан | Ростов-на-Дону | 3 | 36,5 | 6 606,0 | 172 118,82 | 01.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 26. | Түбән Кама | Ростов-на-Дону | 2 | 22 | 7 089,0 | 189 251,89 | 01.01.2022 – 31.05.2022 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 27. | Түбән Кама | Краснодар | 3 | 49 | 8 055,0 | 492 722,62 | 01.01.2022 – 30.04.2022 01.10.2022 – 31.12.2022 |
| 28. | Түбән Кама | Нижневартовск | 2 | 24 | 8 538,0 | 403 871,0 | 01.01.2022 – 31.05.2022 |
| | | | 2 | 41 | 8 538,0 | 492 722,62 | 16.07.2022 – 03.09.2022 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 29. | Түбән Кама | Минерал Сулар | 2 | 34 | 8 055,0 | 246 361,31 | 01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 30. | Түбән Кама | Новосибирск | 3 | 88 | 10 470,0 | 237 257,67 | 01.01.2022 – 30.06.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 31. | Казан | Архангельск | 2 | 104 | 6 606,0 | 148 401,0 | 01.01.2022 – 31.12.2022 |
| 32. | Казан | Брянск | 2 | 14 | 6 123,0 | 137 436,0 | 01.01.2022 – 24.02.2022 |
| 33. | Казан | Калуга | 2 | 28 | 5 157,0 | 115 506,0 | 01.01.2022 – 31.03.2022<br>01.06.2022 – 30.06.2022 |
| 34. | Казан | Нарьян-Мар | 2 | 104 | 7 572,0 | 137 374,0 | 01.01.2022 – 31.12.2022 |
| 35. | Казан | Ханты-Мансийск | 2 | 85 | 7 089,0 | 137 374,0 | 01.01.2022 – 31.12.2022 |
| 36. | Казан | Сыктывкар | 2 | 48 | 4 191,0 | 77 979,5 | 20.07.2022 – 31.12.2022 |
| 37. | Казан | Омск | 2 | 67 | 8 538,0 | 246 361,31 | 01.01.2022 – 31.05.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |
| | | | 3 | 39 | 8 538,0 | 246 361,31 | 01.06.2022 – 31.08.2022 |
| 38. | Казан | Саратов | 2 | 25 | 3 225,0 | 92 165,51 | 01.01.2022 – 31.12.2022 |
| 39. | Казан | Чиләбе | 2 | 66 | 4 767,0 | 126 431,65 | 01.01.2022 – 31.05.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |
| 40. | Түбән Кама | Яңа Уренгой | 2 | 77 | 9 504,0 | 403 871,0 | 01.01.2022 – 31.12.2022 |
| 41. | Түбән Кама | Сургут | 2 | 63 | 7 572,0 | 310 249,0 | 01.01.2022 – 31.05.2022<br>01.09.2022 – 31.12.2022 |